КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 3 сентябрь г.Казань № 787

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын оештыру турында» 2019 ел, 23 май, 432 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын оештыру турында» 2019 ел, 23 май, 432 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 28 гыйнвар, 32 нче; 2020 ел, 2 март, 161 нче; 2020 ел, 17 апрель, 303 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасы турындагы нигезләмәдә:

3.1 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«социаль хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итүчеләр реестрына кертелгән, әмма дәүләт йөкләмәсен (заказын) үтәүдә катнашмаган теләсә кайсы оештыру-хокук рәвешендәге юридик затлар һәм индивидуаль эшмәкәрләр (алга таба – юридик затлар һәм индивидуаль эшмәкәрләр).»;

3.2 нче пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«озак вакыт карау системасында катнашучы медицина оешмалары, социаль хезмәт күрсәтү оешмалары, юридик затлар һәм индивидуаль эшмәкәрләр исемлеген билгеләү;»;

3.4 нче пунктта «көндезге төркем» сүзләрен «көндез бүлек» сүзләренә алыштырырга;

4.1 нче пунктның сигезенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Арча, Түбән Кама муниципаль районнарында халыкка социаль хезмәт күрсәтүнең комплекслы үзәкләре, Әлмәт муниципаль районында, Яр Чаллы һәм Казан шәһәрләре муниципаль берәмлекләрендә инвалидларны тернәкләндерү үзәкләре тарафыннан – өлкән яшьтәге гражданнар һәм (яки) инвалидлар өчен көндезге бүлекләрне оештырганда.»;

әлеге карар белән расланган 2020 елда социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танылган өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын оештыруга юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыруны финанслар белән тәэмин итү кагыйдәләрендә:

7 нче пунктта:

икенче абзацта «социаль хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итүчеләр реестрына кертелгән, әмма дәүләт йөкләмәсен (заказын) үтәүдә катнашмаган теләсә кайсы оештыру-хокук рәвешендәге юридик затларга һәм индивидуаль эшмәкәрләргә» сүзләрен «юридик затлар һәм индивидуаль эшмәкәрләр» сүзләренә алыштырырга;

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы халкына социаль хезмәт күрсәтүнең комплекслы үзәкләренә (алга таба – комплекслы үзәкләр), Татарстан Республикасының өлкәннәр һәм инвалидлар өчен интернат-йортларына (алга таба – интернат йортлар), Татарстан Республикасының психоневрологик интернатларына (алга таба – психоневрологик интернатлар) һәм Татарстан Республикасының инвалидларны тернәкләндерү үзәкләренә (алга таба – инвалидларны тернәкләндерү үзәкләре) стационарны алыштыра торган технологияләрне кертү (шул исәптән стационарны алыштыра торган технологияләр кысаларында «Карау мәктәбе» дәресләрен үткәрү өчен кабинетларны җиһазландыру өчен), карауның индивидуаль планнарын типлаштыру, аларны төзүне һәм тормышка ашыруны тикшерүдә тоту өчен, норматив чыгымнарны, мөлкәтне тотуга чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен комплекслы үзәкләрдә, интернат-йортларда һәм психоневрологик интернатларда социаль эш буенча белгечләрнең штат санын арттыру һәм комплекслы үзәкләрдә һәм инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә өлкән яшьтәге гражданнар һәм (яки) инвалидлар өчен көндезге бүлекләр эшчәнлеген оештырганда хезмәткәрләрнең штат санын арттыру максатларында Россия Федерациясе Бюджет кодексының 781 статьясындагы 1 нче пунктының икенче абзацы нигезендә субсидияләр бирүне;».

2. Бу карарның гамәле 2020 елның 1 мартыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин